**Садри Максудиның тууына 135 ел тулу уңаеннан**

# Татар милләтенең арысланы



«Милләт образауный кешеләргә һәм милләт файдасын һәртөрле шәхси мәнафигыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендә кашы дәрәҗәсендә гаҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ».

**Г. ТУКАЙ.**

*(Башы 2012 елның 22нче санында)*

## Садри төрек студентларына китаплар яза

Биредә С.Максуди хокук бүлеге профессоры вазыйфасында 18 ел эшли, ә 1943 елдан Истанбул университетына күчә һәм озак еллар буе анда хокук тарихы укыта. Аның «Хокук тарихы» дәреслеге 1927, 1928,1931 елларда берничә кат басылып чыга, ә «Гомуми хокук тарихы», «Төрек тарихы һәм хокук», «Хокук фәлсәфәсе», «Теократик дәүләт һәм лаик дәүләт» кебек хезмәтдәреслекләре 1937-1947 елларда һәркайсы берничә мәртәбә басыла һәм хокук факультетында укучы студентларга озак еллар буенча дәреслек булып хезмәт итә.

Дөньяның иң данлыклы университетларыннан булган Сорбоннада укыган С.Максуди хокук фәне өлкәсендә үз заманының иң зур, абруйлы белгечләреннән саналган. Аның хокук фәненең теоретик нигезләрен ачкан, андагы проблемаларны яктырткан бу хезмәтләре дөньякүләм әһәмияткә ия булганнар.

Ә инде 1947 елда басылган «Төрек тарихы һәм хокук» исемле хезмәтенә Татарстанның хокукый һәм гамәли законнарын эшләүче белгечләребез игътибар итсә, яхшы булыр иде. Чөнки С.Максудиның әлеге хезмәте төрек халкы белән тугандаш татар халкының гореф-гадәтләренә, әхлакый законнарына, этик нормаларына да нигезләнеп язылган.

## Садри төрекләргә яңа әлифба язып бирә

Ул әлеге мәкаләләре белән төрек теленең үсеше, аны гадиләштерү, чит сүзләрдән чистарту, яңа сүзләр ясау һәм яңа әлифбаны гамәлгә кую өчен гаять зур эш башкарган тел галиме буларак та таныла. С.Максуди, үзенең шул мәкаләләрен җыеп, 1930 елда "Төрек теле өчен" дигән китабын чыгара. Китапка сүз башын Мостафа Кемал Ататөрек яза: «Милли хис белән тел арасындагы бәйләнеш бик көчле. Телнең милли һәм бай булуы аркасында милли хис тә бөек була. Төрек теле - телләр арасында иң бае. Үз илен һәм аның килечәген саклап кала алган төрек милләте, билгеле, үз телен чит телләрнең басып алуыннан да саклаячак. 2 сентябрь, 1930 ел. Гази Мостафа Кемал». С.Максудиның төрек мәдәниятында, фәнендә тоткан урынының зурлыгын, әһәмиятлелеген күрсәткән һәм хезмәтенә бирелгән бу бәя аның авторитетының җәмәгатьчелек алдында тагын да күтәрелүенә сәбәп була.

## Садри Максуди төрек тарихын яза

С.Максуди, үзенең бар гомерен төрки халыкларның тарихын өйрәнүгә багышлаган Зәки Вәлидидән кала, төрек тарих фәнен үстерүгә дә иң зур өлеш керткән галимнәрнең берсе булып санала. Төркиягә күчеп килгәч тә, С.Максуди «Төрек учаклары» җәмгыятенә әгъза булып керә, һәм 1927 елда әлеге җәмгыятьнең Мәдәният һәм фән буенча комиссиясенә сайлана. Җәмгыятьнең 1930 елның 27 апрелендә уздырылган корылтаенда ул Тарих академиясе төзәргә кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыга һәм үзенең тәкъдимен яклап, озын һәм дәлилле чыгыш ясый. М.Кемалга аның бу тәкъдиме ошый һәм озак та үтми әлеге Комиссия төзелә. Комиссия төзелү белән төрки халыклар һәм алар эчендә төрек халкының яңа тарихын язу буенча Кемал җитәкчелегендә кызу эш башлана. С. Максуди үзе «Искетлар-сакалар» һәм «Урта Азиядәге төрки дәүләтләр» дигән бүлекләрне язарга алына. Аның бу хезмәтләре аерым китаплар булып, 1938 һәм 1934 елларда басылып чыгалар.

## Садри төрек Тарих Академиясенә нигез сала

Аның 1924 елда иртәдән кичкә кадәр Берлинның Милли китапханәсендә басылып эшләвенең файдасы була: Төркиядә аның «Искетлар - сакалар» (1938 ел), «Урта Азия төрек дәүләтләре» (1934 ел), «Төрек тарихы вә хокук» (1947 ел) исемле китаплары дөнья күрә. Төрки халыкларның тарихын өйрәнү, бу шанлы тарихны Европа илләре халыкларына да таныту теләге аңарда Тарих Академиясе төзү кирәклеге турындагы фикерне уята, һәм ул Милләт вәкиле булган елларында әледән-әле бу фикерен матбугат битләрендә, Милләт мәҗлесләрендә да кузгаткалап тора. Шулай итеп, ул әле 1950 елларда соң гына төзеләчәк әлеге Академиягә нигез салырга, аның төзелешенең, эшчәнлегенең төп принципларын билгеләргә тырыша. «С.Максуди төрек тарихын яңадан язып, тарих хакында милли аңны, карашны үстерүгә зур өлеш кертте, милләтчелекне төркичелек дип аңлатты һәм тарихта үзенең эзен калдырды» (С.Максудиның тууына 115 ел уңае белән уздырылган конференциядә Г.Пултар ясаган докладтан). Төркиядә хәзер яши һәм эшли торган «Тарих җәмгыяте» исә аның әнә шул тырышлыгы нәтиҗәсе булып тора. (Әлеге «Тарих җәмгыяте» төзүдә Йосыф Акчура да зур көч куйган, ул әлеге җәмгыятьнең беренче рәисе булган һәм 1932 елда уздырылган Беренче Төрек тарих конгрессының эше белән дә рәислек иткән).

## Садри Максуди - сәясәтче

Төркиядә Ататөрек вакытында С.Максуди сәясәт белән дә шөгыльләнә, өч мәртәбә Төркия парламентына депутат булып сайлана. Бер мәртәбә Й.Акчура белән бергә эшли. Гомере буе Й.Акчураны хөрмәт иткән һәм аны үзенең дусты санаган С.Максуди аның үлемен авыр кичерә (1934 ел). Аңа багышлап язган «Дустым Йосыф Акчура» дигән мәкаләсендә ул аның сәяси эшчәнлегенә зур бәя бирә. Барлык төрки халыклар өчен дә бәйсезлек, милли үсеш чоры килачәк һәм Й.Акчура кебек милләтебез өчен яшәгән шәхесләрнең үлмәс исемнәре онытылмаячак ди. Й.Акчураны ул төркилек идеалына бертуктаусыз хезмәт иткән үз милләтенең бөек улы, дип атый.

## Садри Максуди демократик партия төзүдә катнаша

1946 елда Төркиядә Демократлар партиясе төзелә. Бу партиянең төзелүендә С.Максудиның да өлеше зур, чөнки ул дәүләтнең демократик килачәгенә якты өметләр баглап, кичке «Соң сәгатьтә» гәҗите битләрендә һәр атна саен диярлек демократия, күппартиялелек, гражданлык хокуклары турында гади халыкка аңлаешлы телдә язылган күпсанлы мәкаләләрен бастыра. Аның бу мәкаләләре төрек халкының төрле катлаулары арасында әлеге мәсьәләләргә карата зур кызыксыну уята, Максудины гади халык арасында да киң танытуга һәм аның авторитетының тагын да күтәрелүенә китерә. һәм ул 1950-55 елларда Бөек Милләт мәҗлесенә Милләт вәкиле булып демократлар партиясенең Анкара бүлегеннән сайлана. Инде Милләт мәҗлесендә тел мәсьәләләре каралганда, хокук буенча кануннар тикшерелгәндә дә Төркиянең иң абруйлы сәясәтчесе, олы галиме булган С.Максуди Ареалның салмак, әмма көчле, вәкарьле тавышы яңгырый. С.Максуди 50 нче елларның урталарына кадәр Төркия һәм Европа сәясәтендә күренекле урын били. Төркия делегациясе составында Милләтләр лигасы эшендә катнаша, Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң төзелгән Европа советында да Төркия парламенты делегациясе җитәкчесе буларак бик актив эшли. Европа Советында ул Европа федерациясе Конституциясен язу өчен төзелгән комиссиягә сайлана, дөньядагы төрки дәүләтләрнең мөнфәгатьләрен дә әченә алган Европа федерациясе Конституциясен яза, аны Комиссия утырышына тәкъдим итә, үз фикерләрен дәлилләп, кайнар чыгышлар ясый һәм Комиссия әгъзалары ул язган Конституциянең төрки дәүләтләргә кагылышлы параграфлары белән килешергә мәҗбүр булалар.

## Миллият тойгысының социологик әсаслары

С.Максудиның Төркия республикасының иң абруйлы, танылган сәясәтчеләреннән булуын күрсәткән бер факт: 1955 елда президент сайлаулары вакытында президентлыкка күрсәтелгән 5 кандидатураның берсе Садри Максуди Ареал була. С.Максуди моны төрек җәмәгатьчелегенең үзенең күпьеллык мәдәни, фәнни, сәяси эшчәнлегенә булган бәясе дип кабул итә һәм олы яшьтә булуын сәбәп итеп кандидатурасын ала.

С.Максуди 1955 елда гына сәясәттән китә һәм үзенең калган гомерен бары тик фәнгә генә багышлый. Аның соңгы гыйльми хезмәтләренең берсе «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дип атала. С.Максуди үзе бу хезмәте турында: «Миллиятчелекнең, миллиятнең асылын милләтләрнең яшәешендәге әһәмиятле ролен бәйле рәвештә социологик күзлектән карап тикшергән мондый әсәр төрки телләрдә дә, Европа телләрендә дә әлегә юк», дип күрсәтеп һәм еллар дәвамында миллияткә кагылышлы мәсьәләләр тирәсендә алып барылган эзләнүләр һәм тикшеренүләр нәтиҗәсендә тупланган фикерләрен төрки халыкларга җиткерү максаты белән язылды, дип билгеләп уза. Бу җитди, фәлсәфи хезмәт бөек милләтченең үзеннән соңгы буыннарга - милли тәрәккыят юлында үз халыкларына хезмәт итәчәк буыннарга васыяте сыйфатында карала ала. «Анда милләт һәм милли мөнәсәбәтләр проблемасына тирән теоретик анализ ясала. С.Максудиның бу китапта төрле дәлилләр белән нигезләнеп бәян ителгән фикерләре милли мәсьәләләрне тикшергәндә, милли идеологиянең ориентирларын билгеләгәндә, методологик таяныч ролен үти алалар».

## Татар баласы төрек халкы улы булып үлә

С.Максуди 1957 елның 20 февралендә Истанбулда вафат була. Ул көннәрдә Төркиянең барлык газеталары кайгы сүзләре белән чыга, аның гаиләсенә Европаның төрле илләреннән, Төркия дәүләт җитәкчеләреннән килгән кайгы телеграммаларында, аның үлеме уңае белән матәм мәкаләләре басылган газеталар Төркия үзенең зур галимен, дәүләт эшлеклесен һәм сөекле улын югалтты, дип язалар. Дөньяның киң җәмәгатьчелеге аны олы дәүләт эшлеклесе, төрек халкы исә аны үзенең улы, дип таный.

## Истанбулда татар Садри Максуди исемендәге урам бар

С.Максуди 21 февральдә Истанбулда җирләнә, табуты куелган мәчет янына аның белән хушлашырга дип, дистәләрчә мең кеше җыела. Аның гәүдәсе салынган табутны шифаханәдән Баязит мәчетенә, аннан ул эшләгән университетка кадәр кулга күтәреп алып килаләр. Ә табут исә Төркия флагына төрелгән була. Бу төрек хөкүмәтенең Төркия республикасы сәясәтендә мөһим роль уйнаган, мәдәниятында, фәнендә зур эшләр эшләгән танылган сәясәтчегә, олы галимгә күрсәткән ихтирамы, олы хөрмәте була. Аның кабере бүген дә кадерләп саклана, аңа зиярәт кылына. Истанбулда С.Максуди исемендәге урам да бар.

## Төрекләр Садри Максудины зурлыйлар

С.Максудиның 1925 елдан соңгы эшчәнлеге турында Төркиядә зур-зур хезмәтләр язылган, кызы Адилә Аиданың «Садри Максуди Ареал» исемле китабы чыккан. Инде менә 40 елдан артык һәр ел саен 20 февраль көнне Төркиянең җитди гәҗитләрендә аны искә алу мәкаләләре чыгып килә, ә «Төрек юрду» журналы 1957 елдан башлап, һәр ел саен үзенең февраль санында С.Максудига багышланган материаллар биреп бара.

С.Максуди - гомерен татар халкы, мөселман халыклары һәм төрек халкына хезмәт итүгә багышлаган олуг шәхесләребездән. Төрек дәүләте тарихына ул: «С.Максуди Төркия дәүләтен ныгыту буенча мәгърифәтче вазыйфасын үтәде, үзенең киңәшләре, фикерләре һәм фәнни эзләнүләре белән төрек халкына хезмәт итте, файдалы эшләр башкарды», дигән бәя алып кереп калды. Татар халкы тарихында да Садри Максудиның татар милләте өчен башкарган эшләре үзенең хаклы бәясен алырга, яшь буыннарга җиткерелергә тиеш.

**Мәгълүматны**
**Шамил БАҺАУТДИН туплады.**